РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«18» май 2022г. с. Тюлячи № 97

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 маендагы 96 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында 2021-2022 еллар ягулык сезоны тәмамлану турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Теләче муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү учреждениеләренең 2022 елның 18 маендагы гаризаларын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, уртача тәүлек температурасы +8 °С тан түбәнәюгә бәйле рәвештә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 маендагы 96 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында 2021-2022 еллар ягулык сезоны тәмамлану турында» карарына (алга таба текст буенча - карар) үзгәреш кертергә, 1 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итеп:

«1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында 2021-2022 еллар ягулык сезонын 2022 елның 16 маеннан тәмамларга, Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегендә, Иске Җөри авыл җирлегендә урнашкан муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләреннән, Үзәк авыл җирлегендә урнашкан муниципаль белем бирү уреждениеләреннән тыш.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин